Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Кизләү авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«24» ноябрь 2020 ел № 5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 24 ноябрендә узган: «Киекле авыл җирлегенең Кизләү авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан кала, балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
Кизләү авылында су җыю скважиналарын тоту өчен, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр, товарлар сатып алу.

Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту, таш, ватык кирпеч, грунт, вак таш, ком (сатып алу, ташу, җәю).

Кизләү авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр, товарлар сатып алу.

Кизләү авылы зиратын төзекләндерү һәм сезонлы тоту (коймаларны ремонтлау, агач кисү, үлән чабу).

Кизләү авылында янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру, урнаштырылган гидрантларны ремонтлау) халыкның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу.

Кизләү авылында массакүләм һәм спорт чараларын оештыру һәм уздыру» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 476 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 355 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 269 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 86 катнашучысы тавыш бирде.
Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Кизләү авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Киекле авыл җирлегенең Кизләү авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан кала, балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган

акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Кизләү авылында су җыю скважиналарын тоту өчен, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр, товарлар сатып алу.

Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту, таш, ватык кирпеч, грунт, вак таш, ком (сатып алу, ташу, җәю).

Кизләү авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр, товарлар сатып алу.

Кизләү авылы зиратын төзекләндерү һәм сезонлы тоту (коймаларны ремонтлау, агач кисү, үлән чабу).

Кизләү авылында янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру, урнаштырылган гидрантларны ремонтлау) халыкның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу.

Кизләү авылында массакүләм һәм спорт чараларын оештыру һәм уздыру» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Кизләү авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Р.А.Заһертдинова

Киекле авыл җирлеге башлыгы<br>вазыйфаларын башкаручы Р.Ә. Заһертдинова